СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru


**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 21 » декабрь 2018 ел** **№ 21**

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлегендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына таянып, гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Яңасала авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Яңасала авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халык тыңлаулары халык, Яңасала авыл җирлеге Советы (алга таба - Совет), Яңасала авыл җирлеге башлыгы (алга таба - башлык) яисә контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә.

2) 5 статьяның 1 өлешендәге 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңасала авыл җирлеге башлыгы яки контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә торган гавами тыңлаулар Яңасала авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә».

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл җирлеге башлыгы А.И. Сафин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯНГА-САЛСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ
ЯНГА-САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003024